

Татар кешесе гомер-гомергә тырыш, эшкә маһир һәм кул эшенә оста булган. Хәзерге вакытта да татарлар арасында кулыннан ботен эш килvче осталар кvп. Андыйлар Ләмберәдә дә бар. Аларнын берсе – кул остасы, тимер белән эшләvче Шамиль Зәки улы Коньков.
Ул Краснослободск шәһәрендә туган. Әнисе биредә укытучы булып эшләгән, биредә кияvгә чыккан. Нурия апасы һәм ике игезәк Шамиль белән Камиль дә Краснослободскта туганнар. Әмма биредә гомер итәргә туры килми Коньковларга, Черемиш авылына кvчеп киләләр. Ильяс Фәйзулла улы дигән бабалары кызына, искерәк кенә булса да, ой сатып ала, аны янарта һәм кvпбалалы гаиләне шунда урнаштыра.      Шамиль Черемиш топ мәктәбендә белем алгач, Ләмберәгә урта белем алырга дип юллана. Шунда бер сыйныфка тvбән укыган булачак тормыш иптәшен – Галия Аббяс кызы Байбикова белән танышалар. Балалыктагы яратуы олы мәхәббәткә әйләнеп vсә. Шамиль Зәки улы ике ел Советлар армиясендә Германиядә хезмәт итә, ә Галиясе аны котеп кала. Алар бу хисне гомер буе саклыйлар. Ул: «Балачактагы дуслык мәхәббәткә кадәр vсте дип әйтсән дә ярый, - искә ала Шамиль Закиевич, - бу якты хисләрне, сынаулар vтеп, гомер буена саклап калдык. Мин бит ике ел Германиядә хезмәт иттем, ә булачак тормыш иптәшем тvземлек белән котте».
Армиягә кадәр Шамиль Зәки улы ундvртенче СПТУда кин профильле механизатор һәм шофер профессияләрен vзләштерә. 1980нче елда демобилизацияләнгәч, Черемиш авылы икенче бригадасында йок машинасы йортvчесе булып эшкә урнаша. Бригадир Гафар Хасян улы Прянков яна хезмәткәре белән бик тә канәгать була. Теләсә нинди эшне жин сызганып эшли һәм зур жаваплылык белән башкара торган була Шамиль Зәки улы. Сыер савучыларны тан ату белән жәйләvгә илтv булсынмы, чәчvгә орлык ташу булсынмы, комбайннан ипи ташулар – барысын да тырышып башкарган хезмәткәр. Шамильнен эшен кvзләгән элекке колхоз председателе Василий Васильевич Тулаев Ләмберәгә кvчәргә дип тәгъдим ясый. Коньковлар тәгъдимне кабул итә. Башта яшәгән йортлары сокланырлык булмый, әмма озакламый колхоз vзләренә әйбәт йорт сатып ала. Яна урында чын-чынлап утырып кала бу гаилә. Шулай язмыш торле сукмаклардан йортә. Тырыш хезмәткәр бvгенге производствода да зур хормәттә. Шамиль Зәки улы Коньков слесарь да, тимерче дә. Тимерчеләр бvген модада тvгел, диярсез. Ул: «Барлык нәрсә механизацияләнгән чорда атлар тагаларга юк инде,- дип колә язма героебыз, әмма тимерчесез булдырып булмый шундый гасырда да. Әйтеп китик, жир эшкәртv техникасын кайвакытта нәкъ тимерче генә тозәтә ала. Тормага тимердән «теш» кою булсынмы, аны тиешле урнысына урнаштыру дисе-гезме – барысы да тимерче эше ул.

Кайнар цехта эшләvче тимерчеләрнен тагы кvпторле эшләре бар. Культиватор тәпиләрен жайлаштыру һәм башка эшләр тимерче кулы астыннан vтә».
Бvген шәхси хужалыкларда чынлап та тимерчеләргә сорау артты, чонки сәнгатьчә тимер чукып торле әйберләр ясау хәлле хужаларда хөрмәттә. Матур бизәкләр белән тимердән койган капкалар, я булмаса, тимерне чукып ясаган урындыклар һәм кәнәфиләр, бакча кирәк-яраклары...
- Тимерне чукып торле бизәкләр тошерелгән vзенчәлекле сурәтләр ясарга була; чvлмәкләрне кем коймаган диләр бит әле?.. Әмма производствода мондый эшләр белән шогыльләнергә килешми. Ойдә тимер чыбыклардан  урындык эшләп карадым, бик тә матур килеп чыкты. Лаеклы ялга чыккач, бәлкем бу эш белән шогыльләнермен; ижади, кызыклы һәм мавыктыргыч эш бу. Мәсәлән, выхлопной клапаннан бvләккә башкарылган пычак - vзе сәнгать эше, - ди Шамиль Зәкиевич.
Бvген ул бортекле ашлык утырту белән мавыга – биш еллап инде унышка нигез сала. Алда шикәр чогендерен, кукурузаны утыртасылары бар. Тырыш хезмәте турында башкалар да унай фикердә. «Хормәтле хезмәткәр һәм бик тә жаваплы кеше ул, - ди Шамиль Зәки улы Коньков турында ООО «Нива»да механик булып хезмәт иткән Наиль Аббяс улы Алукаев, - дисциплинаны бик тә ярата. Кушылган эшнен һәрберсен тырышып башкара, жиренә житкереп».
Гади кешеләрнен тормышы бик ук жинелләрдән тvгел, әмма ул бvгенге тормышы белән канәгать; бvтән тосле яшәргә теләмәс тә идем, ди Шамиль Зәки улы Коньков. Ул 1981 елда ойләнә, дидек. Тиздән, бер-бер артлы Мараты белән Алсуы туа. Марат, әтисе тосле, кvгәрченнәр белән кызыксына. Бvген оныгы Ренат та бу кошларга мәхәббәт белән яши; бер минут буш вакыты булдымы – ул кvгәрченлектә. Шамиль Зәки улынын балалары бvген vз йортлары белән, vз гаиләләре белән яшиләр. Кызы Алсунын да кыз бала белән малай игезәге туган. Бу аларнын хатын-кыз линиясе буенча буыннар vзенчәлеге. Шамиль Зәкиевечнен игезәк Камиль браты бар, кызынын да игезәк балалары туган. Мона бабакалары Шамиль бик тә шат. «Киявемнен дә куллары алтын; белмәгән эше юк, ахрысы. Квартирамны да бvгенге евроремонт дигәннәренчә ясап бирде. Алар да уллы һәм кызлылар», - ди балалары турында тимерче язма героебыз. «Юкка гына бу жирдә яшәмәдем, икән,- ди колемсерәп ул, - балалар безнен дәвамыбыз, аларда яшәvнен мәгънәсе».

**Н.Хәлил**